**КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЛЕЛЬВИЖ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«1» февраль 2022 ел № 4

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 16.1 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Әлеге карар үз көченә кергән көннән түбәндәгеләрен үз көчен югалткан дип танырга:

«Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән аерым башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Советының 2017 елның 05 сентябрендәге 19 номерлы карары;

«Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Советының 2017 елның 05 сентябрендәге 19 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән аерым башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында» Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Советының 2018 елның 07 ноябрендәге 24 номерлы карары;

«Кукмара муниципаль районы Советының 2017 елның 05 сентябрендәге 19 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленнән аерым башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт алу тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәреш кертү турында» Кукмара муниципаль районы Лельвиж авыл җирлеге Советының 2018 елның 16 маендагы 10 номерлы карары.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Э.Ю. Игнатьева

ОГРН 1021607752...
ИНН 1623003890